ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

2023 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советында закон проекты эшенең якынча планы турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. 2023 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советында закон проекты эшенең якынча планын расларга (кушымта итеп бирелә).

2. Закон чыгару инициативасы хокукына ия субъектлар 2023 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советында закон проекты эшенең якынча планы нигезендә закон проектларын үз вакытында әзерләүне һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советына кертүне тәэмин итәргә тиеш.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының тиешле комитетлары эшчәнлеген җайга салучы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасарлары 2023 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советында закон проекты эшенең якынча планына кертелгән закон проектларын әзерләү срокларын үтәүне контрольдә тотуны билгеләргә тиеш.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре,
2022 елның 15 декабре
№ 1739-VI ДС

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советының
2022 елның 15 декабрендәге
1739-VI ДС номерлы
карарына кушымта

**2023 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советында закон проекты эшенең якынча планы**

| № т/б | Проектның исеме | Закон чыгару инициативасы хокукы субъекты | Проектны Татарстан Республикасы Дәүләт Советына тапшыру вакыты |
|---|---|---|---|
| | **1. Дәүләт корылышы** | | |
| 1 | «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы проекты (җир кишәрлекләреннән Сосновский балтырганын бетерү чараларын уздырмаган өчен җаваплылык билгеләү өлешендә, шулай ук муниципаль җир контроле органнарына күрсәтелгән административ эшләрне карау вәкаләтләрен бирү хакында) | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитеты Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитеты | II квартал |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 2 | «Аерым муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен үзгәртү һәм «Буа муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты (Буа шәһәре муниципаль берәмлеге, Түбән Наратбаш, Татар Буасы һәм Ырынгы авыл җирлекләре территорияләренең чиктәш чикләрен үзгәртү өлешендә) | Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советы | II квартал |
| 3 | «Татарстан Республикасы Сайлау кодексына һәм Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы проекты (закон актларының аерым нормаларын «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль закондагы үзгәрешләргә туры китерү өлешендә) | Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе | IV квартал |
| 4 | «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты (муниципаль норматив хокукый актларга (муниципаль норматив хокукый актлар проектларына) экспертиза (җайга салу йогынтысын бәяләү) үткәрү мәҗбүри булган муниципаль районнар һәм шәһәр округлары исемлеген төгәлләштерү өлешендә) | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитеты | IV квартал |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 5 | «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламенты турында» 2004 елның 26 февралендәге 2632 номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары проекты (Татарстан Республикасы законнарына туры китерү өлешендә) | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты Ш.Ш. Яһудин | IV квартал |
| 6 | «Казан шәһәре районнары чикләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты (Казан шәһәре Совет районы территориясенә Казан шәһәре муниципаль берәмлегендә урнашкан «Фәнни шәһәрчек» территориясен һәм Казан шәһәре муниципаль берәмлегендә урнашкан «Курган» зират комплексы территориясен, Казан шәһәре Идел буе районы чикләренә Казан шәһәре муниципаль берәмлегендә урнашкан «Динамо» биатлон комплексы территориясен кертү, шулай ук Нурсолтан Назарбаев урамыннан алып Вахитов мәйданына кадәр Казан шәһәре Вахитов һәм Идел буе районнары чикләрен чагылдыруда техник хатаны төзәтү максатыннан Казан шәһәре районнары чикләрен үзгәртү өлешендә) | Казан шәһәр Думасы | IV квартал |
| **2. Икътисадый сәясәт** | | | |
| 7 | «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты (күпфатирлы йортларда капиталь ремонт буенча хезмәт | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Торак сәясәте һәм инфраструктура үсеше комитеты | I квартал |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | күрсәтүләрнең һәм (яисә) эшләрнең капиталь ремонт фонды акчалары исәбеннән финансланып башкарыла торганнарының исемлеген төгәлләштерү өлешендә) | | |
| 8. | «Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты (капитал салуларны яклау һәм хуплау турындагы килешүләр кысаларында гамәлгә ашырыла торган инвестиция проектларына дәүләт ярдәме чаралары күрсәтү шартларын төгәлләштерү өлешендә) | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитеты | I квартал |
| 9 | «Татарстан Республикасында ветеринария эше турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты («Ветеринария турында» Россия Федерациясе Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 6 декабрендәге 397-ФЗ номерлы Федераль законга (терлекчелек продуктларын җитештерү һәм саклау өчен каралган биналарны (төзелмәләрне, корылмаларны) планлаштыру һәм төзү мәсьәләләрен җайга салу өлешендә), «Ветеринария турында» Россия Федерациясе Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 28 июнендәге 221-ФЗ номерлы Федераль законга (Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең ветеринария өлкәсендәге органнары вәкаләтләрен төгәлләштерү өлешендә), «Ветеринария турында» Россия Федерациясе Законының 19 статьясына үзгәреш кертү хакында» 2022 елның 28 июнендәге 222-ФЗ номерлы Федераль законга (аеруча куркыныч хайван авырулары | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитеты | I квартал |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | чыганакларын юкка чыгарганда хайваннарны һәм (яисә) терлекчелек продукциясен алып китү мәсьәләләрен җайга салу өлешендә) туры китерү өлешендә) | | |
| 10 | «Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы проекты (җирлекнең, муниципаль округның яисә шәһәр округының җирле үзидарә органы тарафыннан Россия Федерациясе субъекты билгеләгән массакүләм мәгълүмат чараларында авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән җир кишәрлегенә гомуми өлешле милек хокукындагы өлешләр күләмнәрен гектарлар яисә балло-гектарлар, гади ялгыз вакланма рәвешендә билгеләү нәтиҗәләрен раслау турындагы карарны бастырып чыгаруга таләпләр билгеләү өлешендә) | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитеты | I квартал |
| 11 | «2022 елгы Татарстан Республикасы бюджеты үтәлеше турында» Татарстан Республикасы законы проекты (Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 97 статьясы нигезендә) | Татарстан Республикасы Президенты | II квартал |
| 12 | «2022 елгы Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты үтәлеше турында» Татарстан Республикасы законы проекты (Татарстан Республикасы Бюджет кодексының $97^6$ статьясы нигезендә) | Татарстан Республикасы Президенты | II квартал |
| 13 | «Татарстан Республикасында нәселле терлекчелек турында» Татарстан Республикасы законы проекты (яңа закон кабул итү һәм актуальләштерү, федераль законнарга туры китерү зарурлыгына бәйле рәвештә «Татарстан Республикасы терлекчелегендә нәсел эше турында» | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты | II квартал |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | 1996 елның 28 мартындагы 482-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын үз көчен югалткан дип тану) | | |
| 14 | «Татарстан Республикасында архив эше турында» Татарстан Республикасы Законының 22 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты (дәүләт архивларының һәм муниципаль архивларның электрон рәвештә Россия Федерациясе Пенсия фондының территориаль органнары белән пенсияләр һәм башка социаль түләүләр билгеләү өчен кирәкле булган мәгълүмат алышу буенча хезмәттәшлеген оптимизацияләү өлешендә) | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитеты | II квартал |
| 15 | «2024 елга Татарстан Республикасында хезмәт базары үзенчәлекләрен чагылдыра торган региональ коэффициентны билгеләү турында» Татарстан Республикасы законы проекты (патент нигезендә физик һәм юридик затларда хезмәт эшчәнлеген наем буенча гамәлгә ашыручы чит ил гражданнарының физик затлар керемнәренә салым буенча теркәлгән аванс түләүләре күләмен индексацияләү максатларында Россия Федерациясе субъекты законы белән тиешле календарь ел өчен хезмәт базарының региональ үзенчәлекләрен чагылдыра торган коэффициентны билгеләү каралган Россия Федерациясе Салым кодексының $227^1$ статьясындагы 3 пункты нигезендә эшләнә) | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты | III квартал |
| 16 | «Татарстан Республикасы Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы проекты (федераль законнарга туры китерү өлешендә) | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Бюджет, салымнар һәм финанс комитеты | III квартал |
| 17 | «Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге | Татарстан Республикасы | III квартал |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты (федераль законнарга туры китерү өлешендә) | Дәүләт Советының Торак сәясәте һәм инфраструктура үсеше комитеты | |
| 18 | «Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты (авыр йөк транспорты һәм (яисә) зур габаритлы транспорт чарасының автомобиль юлларында хәрәкәте мәсьәләләрен регламентлаштыру өлешендә) | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Торак сәясәте һәм инфраструктура үсеше комитеты | III квартал |
| 19 | «2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы законы проекты (Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 61 статьясы нигезендә) | Татарстан Республикасы Президенты | IV квартал |
| 20 | «2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты турында» Татарстан Республикасы законы проекты (Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 61 статьясы нигезендә) | Татарстан Республикасы Президенты | IV квартал |
| 21 | «Транспорт салымы турында» Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты (Әфганстан Республикасында һәм Төньяк Кавказ регионы территориясендәге хәрби хәрәкәтләр ветераннары исеменә теркәлгән транспорт чараларын салым салудан азат итү турында) | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты И.М. Егоров | IV квартал |

| | | | |
|---|---|---|---|
| **3. Социаль сәясәт** | | | |
| 22 | «Халыкның санитария-эпидемиология иминлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты (санитария-гигиена гыйлеменең асылын ачыклауга һәм санитария-гигиена гыйлеме чараларын гамәлгә ашыру өлешендә Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары вәкаләтләрен билгеләүгә юнәлдерелгән) | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты | I квартал |
| 23 | «Татарстан Республикасында бала хокукларын һәм аның законлы мәнфәгатьләрен яклауның аерым чаралары турында» Татарстан Республикасы Законының 4 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты (балаларның сәламәтлегенә яисә үсешенә зыян китерә торган мәгълүматның исемлеген киңәйтүгә юнәлдерелгән) | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты | I квартал |
| 24 | «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты (репрессияләргә бәйле рәвештә торак урынын югалткан реабилитацияләнгән затларга социаль ярдәм чаралары билгеләү өлешендә) | Татарстан Республикасы Прокуроры | II квартал |
| 25 | «2024 елга Татарстан Республикасында мәктәпкәчә белем бирүнең уку-укыту программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль мәгариф оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә белем алуга хокукларны | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты | III квартал |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен финанс белән тәэмин итү нормативларынраслау турында» Татарстан Республикасы законы проекты («Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 8 статьясы һәм «Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимиятне оештыруның гомуми принциплары турында» 2021 елның 21 декабрендәге 414-ФЗ номерлы Федераль законның 44 статьясы нигезендә) | | |
| 26 | «2024 елга Татарстан Республикасы гомуми белем бирү һәм һөнәри белем бирү оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем, шулай ук өстәмә белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен финанс белән тәэмин итү нормативларын раслау турында» Татарстан Республикасы законы проекты («Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 8 статьясы һәм «Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимиятне оештыруның гомуми принциплары турында» 2021 елның 21 декабрендәге 414-ФЗ номерлы Федераль законның 44 статьясы нигезендә) | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты | III квартал |
| 27 | «Татарстан Республикасында гражданнарны патриотик тәрбияләү турында» Татарстан Республикасы законы проекты (Татарстан Республикасы гражданнарын патриотик тәрбияләү системасының эшләвен тәэмин итү, ил язмышы өчен граждан җаваплылыгын арттыруга | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты | III квартал |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | шартлар тудыру, тотрыклы үсеш, милли иминлек мәсьәләләрен хәл итү өчен җәмгыятьнең берләшү дәрәҗәсен арттыру максатларында) | | |
| **4. Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасында Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативалары** | | | |
| 28 | «Атмосфера һавасын саклау турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында (Федераль законның 25 статьясы нормаларын төрлечә ачыклауны бетерү, закон таләпләрен формалаштыруны бертөрлелеккә китерү максатларында, шулай ук бизнеска административ йөкләнешне киметү максатында) | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты А.Г. Хәбибрахманов | I квартал |
| 29 | «Куркыныч җитештерү объектларының сәнәгать иминлеге турында» Федераль законның 9 статьясына үзгәрешләр кертү хакында (14 абзацка «нефть һәм газ ятмалары скважиналарыннан тыш» сүзләрен өстәү максатыннан) | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты А.Г. Хәбибрахманов | I квартал |